**ПОСЕЛКОВЫЙ СОВЕТ**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ**
**ПОСЕЛОК ГОРОДСКОГО ТИПА**
**ТЕНИШЕВО**
**КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

---

# КАРАР

**шпт. Тенишево** **№ 134-рс**

**Поселок Советы тарафыннан 2025 елның 16 июне кабул ителде**
**2025 елның 16 июне бистәсе башлыгы тарафыннан имзаланган**

Бишенче чакырылыш "Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенишево шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге Советы депутатларын сайлауларны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы карарының 105 статьясындагы 1 өлеше белән, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенишево шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставының 16 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тенишево шәһәр тибындагы поселогы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Бишенче чакырылыш «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенишево шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы депутатларын сайлауларны 2025 елның 14 сентябренә билгеләргә.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат такталарында халыкка җиткерергә:
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, штп. Ленин ур., 8 й.;
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, штп. Пионер ур., 18 й.;

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча «Идел таңнары» газетасында бастырып чыгарырга һәм Кама Тамагы муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга..

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы

муниципаль районының Тенишево
шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге башлыгы,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районының Тенишево шәһәр тибындагы
поселогы» муниципаль берәмлеге Советы Рәисе И.И. Яруллин